**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 263 28.04.2015ел

Аксубай муниципаль районы җирлекләре бюджетларына төзелгән килешүләр нигезендә вәкаләтләр бюджеттан тапшырыла торган бюджетара трансфертларны исәпләү методикасы турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.4 статьясына таянып, Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.1 нче кушымта нигезендә төзелгән килешүләр нигезендә Аксубай муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына Аксубай муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга тапшырыла торган бюджетара трансфертларны исәплəү методикасын расларга.

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль район Советының Бюджет, салымнар һәм Финанслар, җыемнар, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе К.К. Гилманов

Аксубай муниципаль районы
Советы 28.04.2015 ел № 263 карарына
1 нче кушымта.

Аксубай муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына төзелгән килешүләр нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бюджетара трансфертларны исәпләү методикасы.

. 1.Әлеге Методика вәкаләтләр тапшырылган очракта Аксубай муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар күләмен исәпләү максатларын һәм тәртибен билгели:

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 1ст14 пунктына туры килүче җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү буенча - җирлек халкын су белән тәэмин итү;

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 5ч.14 пунктына туры килүче Федераль законның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 15ч.1 пунктындагы җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү буенча-җирлек халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

2. Бюджетара трансфертлар әлеге методиканың 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча тапшырылган вәкаләтләрне финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә.

3. Бюджетара трансфертларны исәпләү тәртибе гамәлгә ашырыла:

3.1. « Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 часть 14 пунктына туры килүче җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү буенча

- җирлек халкын су белән тәэмин итү:

Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру вәкаләтләрен үтәүгә бюджетара трансфертлар күләме җирле әһәмияттәге әлеге мәсьәлә өлешендә гражданнарның үзара салымы акчаларының 10% күләмендә билгеләнә.

3.2.« Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 5ч.14

пунктына туры килүче әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү буенча-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге вәкаләтен үтәүгә бюджетара трансфертлар күләме җирлекнең бу мәсьәләсе өлешендә гражданнарның үзара салым суммасыннан 10% күләмендә бүленә.

3.3.« Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 15ч.1 пунктына туры килүче әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү буенча - җирлек халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру:

Җирлек халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру вәкаләтләрен үтәүгә бюджетара трансфертлар күләме җирлек гражданнарының үзара салымы акчаларының җирле әһәмияттәге әлеге мәсьәлә өлешендә 10% күләмендә билгеләнә.